КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 11 февраль г.Казань № 94

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче; 2007 ел, 20 апрель, 136 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы; 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2016 ел, 20 февраль, 103 нче; 2016 ел, 6 август, 536 нчы; 2017 ел, 15 июль, 497 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1070 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1126 нчы; 2017 ел, 12 май, 350 нче; 2018 ел, 18 май, 375 нче; 2018 ел, 24 июль, 592 нче; 2018 ел, 8 сентябрь, 762 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1127 нче, 2019 ел, 19 апрель, 311 нче, 2019 ел, 25 декабрь, 1192 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгълүматлаштыру белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән эшләү (01.15*);»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.49$^{4}$ пунктын өстәргә:

«4.1.49$^{4}$. Үз ведомствосындагы оешмаларда хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин